| | |
|---|---|
| **ГЛАВА СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11. 2023 ел. Иске Тәрбит авылы №3

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл җирлеге
Иске Тәрбит авылында
үзара салым кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында .

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 28.07.2004 ел, № 45-ЗР Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп ярашлы рәвештә карар бирәм:

1. 2023 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка һәм 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы ,Үзәк урамы, 25 нче йорт янында һәм Иске Тәрбит авылы, Уральская урамы, 6 нчы йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ике җыеннның беренче этабын билгеләргә.
2. 2023 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка һәм 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы МФЦ бинасында һәм Иске Тәрбит авылы мәктәп бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ике җыеннның икенче этабын билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлегенең Иске Тәрбит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

**а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- материаллар сатып алып урамны яктыртучы утларны ремонтлау;
- территорияне торак пунктнын санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләреннән чистарту;
- **торак пункт территориясеннән авария хәлендәге агачларны кисү һәм чыгару;**

**б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- материаллар сатып алып, су башнясын ремонтлау һәм хезмәт курсэту;
- материаллар сатып алып, сууткэргеч челтэрен ремонтлау;

**в) җирлектәге торак пунктлар чикләрендәге җирле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге ;**

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

**г)ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;**

- зират территориясен саклау, тэзеклэндеру һәм ремонтлау;

3. “Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында” 2023 елның 01 ноябрендэге 3 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл башлыгы карарын юкка чыгарырга.

“риза” “каршы”

4. Әлеге карарны Иске Тәрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Тәрбит авыл җирлеге башлыгы В.Г. Тимофеев